РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 март 2021 ел Кукмара ш. № 41

«2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты проекты турында» 2020 елның 11 декабрендәге 32 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» 2020 елның 11 декабрендәге 32 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының карарын түбәндәге эчтәлекле 12$^{1}$ статьясын өстәргә:

«12$^{1}$. Кукмара муниципаль районының муниципаль мөлкәтен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аларны бирү законнар белән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага алучы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль өстәмә система органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе белән кертелгән югары әзерлек режимының гамәлдә булу чорында исәпләнгән аренда түләүләрен кертү буенча кичектереп тору бирелә.

Аренда түләүләрен түләүне кичектерү шартлары һәм сроклары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының аерым карары нигезендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга».

Район Башлыгы С. Д. Димитриев